Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кәвәл авыл җирлеге Советының егерме беренче утырышы

Кәвәл авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

16 декабрь, 2022 ел № 56

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Кәвәл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү эшен оештыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль законына таянып Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 сентябрендәге 36 номерлы карары (Кәвәл авыл җирлеге Советының 2022 елның 31 мартындагы 35 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Кәвәл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү эшен оештыру турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 статьяның 5 өлешенә «Россия Федерациясе Пенсия фонды», «Россия Федерациясе социаль иминиятләштерү фонды» сүзтезмәсен тиешле килешләрдә «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды» сүзтезмәсенә алмаштырырга;

- 2 статьяның 5 өлешендәге 2 абзацын төшереп калдырырга;

- 2 статьяның 5 өлешендәге 4 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды - вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек очрагында һәм ана булу белән бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминиятләүгә тиешле вафат булган гражданнарны һәм вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек очрагында һәм бала табуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминиятләштерелергә тиешле гражданнарның һәм вафат булган гаилә әгъзаларын вакытлы хезмәткә сәләтсезлек очрагында һәм вафат булу көнендә мәҗбүри социаль иминиятләштерелергә тиешле булган, пенсионер вафат булган гаиләләрнең күрсәтелгән әгъзаларының үлгән көнендә ана булу белән бәйле рәвештә күмүгә;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Кәвәл авыл җирлеге башлыгы М.Х. Камалиев